ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында” Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында” 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:
“$1^1$. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларында катнашучылар составына җирле үзидарә органнарының законнар белән билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи затлары, дәүләт хакимияте органнары вәкилләре кертелә, шулай ук гражданнар, территориаль иҗтимагый җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр вәкилләре кертелергә мөмкин.”;

2) 2 өлештә “законнар белән билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтләр бирелгән” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 18 феврале
№ 7-ТРЗ